КАРАР

**14 декабрь 2021 ел** **№ 2**

**Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

2 пунктның беренче абзацында «500 сум» сүзләрен «850 сум» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле унынчы абзацны өстәргә:

«-Байлангар авылының Гагарин урамына асфальт җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 538 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 272.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 272 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы Байлангар авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

2 пунктның беренче абзацында «500 сум» сүзләрен «850 сум» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле унынчы абзацны өстәргә:

«-Байлангар авылының Гагарин урамына асфальт җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Байлар авыл җирлеге башлыгы: И.Ф. Кәримуллин